Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең
Яңа Нәдер авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

16 ноябрь 2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 12 ноябре 17 сәгать 00 минутта, 2021 елның 13 ноябре 13 сәгать 00 минутта, 2021 елның 14 ноябре 13 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә «Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү максатыннан түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү системасын норматив халгә китерү, сметалар төзү өчен түләү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкен рәсмиләштерү, су белән тәэмин итү системаларын норматив хәлгә китерү өчен җиһазлар сатып алу; урам утларын норматив хәлгә китерү?» сораулары буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1121 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 581 кеше, бу 51% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 418-е «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

гражданнар җыенында катнашучыларның 163-е «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлегенең Яңа Нәдер авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче һәр кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 400 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: су белән тәэмин итү системасын норматив халгә китерү, сметалар төзү өчен түләү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкен рәсмиләштерү, су белән тәэмин итү системаларын норматив хәлгә китерү өчен җиһазлар сатып алу; урам утларын норматив хәлгә китерү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, Яңа Нәдер авылы, Совет урамы, 81 йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче С.М. Миннебаев